# Бөек Җиңүгә- 70 ел.
# Ветераннар белән очрашабыз.



**Сугыш килде безгә сорамыйча,**

**Шакымыйча керде ишектән,**

**Кабатладык шулчак тешне кысып:**

**“Без җиңәргә тиеш ничек тә!”**

Шигырь юлларында әйтелгәнчә күп кенә аналарның газиз балалары, хатын – кызларның сөйгән бердәнбер ярлары шушы дәһшәтле канлы сугышка китәләр.

Бөек Ватан сугышы безнең авылны да читләтеп узмый.Безнең авылдан да Бөек Ватан сугышына барлыгы 155 кеше китеп, 74 е сугыш кырларында ятып кала, ә 81 сугышчы әйләнеп кайта. Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашларыбызның хәбәрсез югалып, билгесезлектә калуы ачыкланды. Аларның исемнәре мәңгеләштерелеп, Хәтер китабына кертелде.

Без Бөек Ватан сугышы ветераннары белән очрашып торабыз. Соңгы вакытта без Бөек Ватан сугышы ветераны Шәйхулла абый белән очраштык. 16 яшьлек егет Бәширов Шәйхулла үз теләге белән Ватанны сакларга китә. Аңа дошманга каршы көрәшнең ахырына кадәр булырга туры килә. Ул бу елларны йөрәк әрнүе белән хәтеренә төшерә.

**Шәйхулла абый, үзегезнең сугыш юлыгыз турында сөйләп үтегез әле?**

- Сугыш ул коточкыч нәрсә. Кайгы һәм күз яшьләре, ятим калганнар, бәхетсез гаиләләр. Миңа да күп авырлыклар кичерергә туры килде.

Аккан су кебек 69 ел вакыт үтеп тә киткән. Әледән-әле искә төшеп торган сугыш чорлары йөрәккә һаман тынычлык бирми. Без күргән михнәтләрне, аналарның түккән күз яшьләрен халкым башка күрмәсен иде.

Үзем 1942 елның август аенда Ватанны сакларга, туган илемне фашист илбасарларыннан азат итәргә киттем. Башта Горький өлкәсендәге лагерьда хәрби укулар үттем. Ноябрь башында Воронеж фронтына туплandык, аннан икенче Украина фронтына берләштек. Фронт командиры маршал Конев җитәкчелегендә Днепр-Ордер елгаларын кичеп Украинаны азат иттек, аннан Польшаны , югалтулар күп булды. Сугыш дәвам итте. Көнчыгыш Пруссияне алганна соң, немецларны үзләренә чигендердек. Шулай итеп, бу канкойгыч сугыш Германияне җиңү белән тәмамланды. Берничә кат яраландым, полкташ дусларым һәлак булды. Әмма без бер вакытта да җиңүгә шанычыбызны югалтмадык. Шуңа күрә барысына да түздек, Җиңү көнен күрергә исән-сау әйләнеп кайтырга насыйп булды.

**Шәйхулла абый, Бөек Ватан сугышында җиңүгә ирешүебезнең сәбәбе нәрсәдә дип уйлыйсыз?**

- Сугыш чорында илебез халкы бер гаиләдәй дус, тату булды, авыл аек булды, арабызда комсыз, явыз, сатлыклар аз булды, һәркем аз сөйләп, күп эшләде, шуңа күрә җиңүгә ирештек.

**Быел Бөек Җиңүгә 69 ел тула, әмма сугышларның тынып торганы юк дисәк, килешерсезме**?

- Әйе, сугышларның тынып торганы юк. Хәзер дә күпме егетләр чит җирләрдә барган сугышларда кан коялар. Әфган, Чечен сугышында күпме асыл егетләребез харап булды. Нигә кирәкте бу сугышлар, кемгә кирәкте, кем гаепле? Бу сорауларга беркем дә җавап бирә алмый әле.

**Шәйхулла бабай, укучыларга нинди теләкләрегез бар?**

-Хәзер мин һәрбер кояшлы көнгә шатланам, балаларым һәм оныкларым бер вакытта да сугышны күрмәсен иде дип ходайдан сорыйм.Ә сезгә,балалар, теләгем шул: олыны-олы, кечене кече итә белегез, бер-берегезгә, әти-әниегезгә, һәркемгә игелекле булыгыз. Тырышып укыгыз. Хезмәтне яратыгыз. Начар гадәтләрне юлдаш итмәгез. Илебез киләчәге сезнең кулларда, без аны сезгә ышанып тапшырабыз.

**Рәхмәт. Без сезгә, Шәйхулла абый, бәхетле , куанычлы озын гомер, шатлыклы көннәр, балаларыгыз һәм оныкларыгыз белән бергә-бергә исән-сау яшәвегезне телибез.**

**Без Җиңүнең 69 еллыгын каршыларга әзерләнәбез.**
**Ә сугышветераннары һәм тыл батырларыкөннән-көн кими бара. Аларга аз гына булса да ярдәмебез тисен иде. Аларга карата мәрхәмәтле, ярдәмчел булыйк.**
**Безнең хәзерге матур, тыныч тормышыбыз өчен көрәшүчеләрне хөрмәт итик. Алар бит бу зур җиңүне үзләренең газиз гомерләре бәрабәренә яуладылар.**
**Авылыбызның күпме асылир-егетләрен йоткан ул рәхимсез сугыш. Киләчәктә илебез тыныч, күгебезаяз, әти-әниебез тигез, тормышлар матур булсын өчен без тарышып укып намуслы, чынкешеләр булып үсәргә тиешбез.**
**Сугышлар булмасын, булмасын! Туган илебездә,матур тормышта бәхетле яшик.**

**Ишниязова Алсинә Инсаф кызы**
**Урманасты Шынталысы урта мәктәбенең**
**9 нчы сыйныф укучысы**